**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО**
**РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**31.01.2019** **№ 190**

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында җирләү буенча гарантияле исемлек нигезендә хезмәт күрсәтү бәясен раслау турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 ел, 6 нчы октябрь 131-ФЗ номерлы Федераль закон, "Мәет җирләү һәм күмү эше турында" 1996 ел, 12 нчы гыйнвар 8-ФЗ Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасында “Күмү һәм җирләү эше турында” Федераль законны тормышка ашыру чаралары хакында” 2007 ел, 18 нче май, 196 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “2019 елга түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында” 2019 ел, 24 нче гыйнвар 32 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТТЕ:

1. 2019 елның 1 нче февраленнән Биектау муниципаль районында җирләү буенча гарантияле исемлек нигезендә хезмәт күрсәтү бәясен, 1, 2 кушымталар нигезендә 5946,47 сум итеп билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының “Җирләү буенча гарантияле исемлек нигезендә хезмәт күрсәтү тарифларын раслау турында” 2018 ел, 1 нче февраль 315 номерлы карарын 2019 елның 1 нче февраленнән үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Биектау муниципаль районы
башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф. Шәйдуллин

Биектау муниципаль районы
башкарма комитеты җитәкчесе
карарына
1 нче кушымта
31.01.2019 № 190

2019 елның 1 нче февраленнән Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында җирләү буенча гарантияле исемлек нигезендә хезмәт күрсәтү бәясе

| Хезмәт күрсәтүнең исеме | Хезмәт күрсәтүнең бәясе *(сумнарда)* |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү. | бушлай |
| 2. Табут һәм җирләү өчен башка кирәкле әйберләрне тәкъдим итү һәм китереп бирү. | 3467,50 |
| 3. Мәрхүмнең җәсәден зиратка китерү | 788,77 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү ) | 1690,20 |
| Барлыгы | 5946,47 |

Биектау муниципаль районы
башкарма комитеты җитәкчесе
карарына
2 нче кушымта
31.01.2019 № 190

2019 елның 1 нче февраленнән Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында җирләү буенча гарантияле исемлек нигезендә хезмәт күрсәтү бәясе

| Хезмәт күрсәтүнең исеме | Хезмәт күрсәтүнең бәясе *(сумнарда)* |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү. | бушлай |
| 2. Мәетне киендерү. | 450,73 |
| 3. Табут һәм җирләү өчен башка кирәкле әйберләрне тәкъдим итү һәм китереп бирү. | 3016,77 |
| 4. Мәрхүмнең җәсәден зиратка китерү | 788,77 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү ) | 1690,20 |
| Барлыгы | 5946,47 |